# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Олыяз авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 2 декабре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылы торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Олыяз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәр бала тәрбияләүче ялгыз аналар, 80 яшькә җиткән һәм өлкәнрәк; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срочная хәрби хезмәткә чакырылган затлар; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларны һәм аларның гаилә әгъзалары керми.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (яктырткычлар сатып алу);

2) урамнарны яктырту җайланмасы ( 5 нче линияне монтажлау , җәяүлеләр коммуникациясен яктырту материаллар сатып алу, смета документациясе төзү);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү ,ремонтлау, карап тоту (асфальт түшәлгән юлларны ремонтлау, юлларны кыш көне карап тоту , юл билгеләрен һәм көзгеләрен сатып алу һәм урнаштыру, смета документациясен төзү, технадзорны гамәлгә ашыру);

4) тротуарларны төзү, ремонтлау ( планлаштыру, куаклыкларны чистарту, вак таш җәю, смета документлары төзү); - яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту ( кыргый куаклардан һәм агачлардан чистарту, ярны ныгыту, материаллар сатып алу, смета документлары төзү.

3. Элеге карарны Олыяз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче

Муниципаль берәмлек башлыгы Р. Ф. Маликов